ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЗУР СӘРДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

22 ноябрь, 2023 ел №26

Физик затларның мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Зур Сәрдек авыл җирлеге советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы территориясендә түләүгә мәҗбүри булган физик затларның салым милеген билгеләү һәм гамәлгә кертү.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:

гаражлар һәм машина-урыннар;

һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки төзелмәләр;

мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясының 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясының 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннар. Ставка салым түләүче сайлаган бер гаражга яки машина-урынга карата билгеләнә;

2) фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә карата 0,2 процент

3) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент:

торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- составына ким дигәндә бер торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

- төзелеп бетмәгән объектлар, әгәр мондый объектларның проектлана торган максаты торак йорт булса;

4) түбәндәгеләргә карата 2 процент:

һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;

5) башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

6) 1,2 процент – 2015 елда;1,5 процент – 2016 елда; 1,8 процент – 2017 елда; 2 процент – 2018 елда һәм алдагы елларда түбәндәгеләргә карата:

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясының 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 10 пунктның икенче абзацында каралган салым салу объектлары

3. Ике фатирдан торган күп фатирлы бер катлы торак йортта фатирга милек хокукы булган физик затларга ташламаны бу фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнгән суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәрберсе өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир гомуми уртак милектә булса, ташлама суммасы уртак милектә катнашучыларның һәрберсе өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама суммасы аның исәбеннән башка исәпләнгән салым суммасыннан артмаска тиеш.

Югарыда күрсәтелгән ташламаны раслый торган документлар буларак, җирле үзидарә органы тарафыннан расланган йортка кадастр паспорты яки күп фатирлы бер катлы торак йортлар исемлеге тора.

4. Түбәндәге физик затларны милеккә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге 5 һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын;

3) Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарны (алга таба – мобилизация буенча чакырылган гражданнар) һәм аларның гаиләләре әгъзаларын (ире/хатыны, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы 23 яшькә кадәрге балалары»);

4) мобилизация буенча чакырылган гражданнарның алар белән бергә яшәүче (яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) ата-аналары.

5) махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзалары (тормыш иптәше, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы 23 яшькә кадәрге балалары);

6) махсус хәрби операциядә катнашучы, алар белән бергә яшәүче (тормыш урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) контракт хезмәте хәрбиләренең әти-әниләре.

Әлеге пунктның 3 - 6 пунктчалары нигезендә салым ташламасына хокуклы гражданнар исемлеге Зур Сәрдек авыл башкарма комитеты тарафыннан салым органына тапшырыла.

5. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына, әлеге карар белән аларның үз көченә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш.

6. Әлеге карарның 4 пунктындагы 3 һәм 4 пунктчалары нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарның 4 пунктындагы 5 һәм 6 пунктчалары нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

8. Әлеге карар законлы көченә кергән көннән алып, Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 32 номерлы карары, «Физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 32 номерлы «Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 30 маендагы 26 номерлы карары,2015 елның 13 октябрендәге 5 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 16 номерлы,2019 елның 28 ноябрендәге 26 номерлы,2022 елның 24 ноябрендәге 35 номерлы карарлар  үз көчен югалта.

9. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы Ф.М.Фаттахов